ГЛАВА
БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.02.2019** Зур Полянка авылы **№ 1**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәр вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затлары тарафыннан, вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә, һәм «Аерым категория затларның беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алуы турында хәбәр итү, бүләк тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларына туры китерү максатларында,

**карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәр вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затлары тарафыннан, вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» Алексеевск

муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге башлыгының 2014 елның 2 апрелендәге 2 номерлы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«муниципаль вазыйфа биләүче зат – депутат, җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булган Зур Полянка авыл җирлеге сайлау комиссиясе әгъзасы, комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш бирү хокукы булган, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлегенең контроль-хисап органы рәисе;»

2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«вазыйфаи хәл яки хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларын башкару белән бәйле рәвештә бүләк алу» – муниципаль вазыйфа биләүче зат, муниципаль хезмәткәр тарафыннан шәхсән яисә арадашчы булган физик (юридик) затлар аша вазыйфаи регламентта (вазыйфаи инструкциядә) каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру кысаларында, шулай ук федераль законнарда һәм күрсәтелгән затларның һөнәри хезмәт һәм хезмәт эшчәнлеге үзенчәлеген билгели торган башка норматив актларда билгеләнгән очракларда, хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларын башкару белән бәйле, шулай ук федераль законнарда һәм күрсәтелгән затларның һөнәри хезмәт һәм хезмәт эшчәнлеге үзенчәлеген билгели торган башка норматив актларда билгеләнгән очракларда, хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларын башкару белән бәйле, шул исәптән беркетмә чаралары, хезмәт командировкаларына һәм хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу».

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, хезмәткәрләр, вазыйфаи хәлләренә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм хезмәт (вазыйфаи) бурычын үтәүгә бәйле башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләкләрдән тыш, физик (юридик) затлардан бүләкләр алырга хокуклы түгел.».

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль хезмәткәрләр әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә, хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә, бүләк алуның барлык очраклары турында, күрсәтелгән затлар анда муниципаль хезмәт үткән яки хезмәт эшчәнлеген башкарган җирле үзидарә органына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы

Зур Полянка авыл җирлеге сайлау комиссиясенә (алга таба – җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясенә) хәбәр итәргә тиеш.».

5 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Вазыйфаи хәл яисә хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларын башкару белән бәйле, хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә 2 номерлы кушымта нигезендә төзелгән бүләк алу турындагы хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә), муниципаль вазыйфа биләгән зат муниципаль хезмәт үткән яки хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган (алга таба – вәкаләтле структур бүлекчәгә (вәкаләтле вазыйфаи зат) җирле үзидарә органының вәкаләтле структур бүлекчәсенә (вәкаләтле вазыйфаи затка), сайлау комиссиясенә бүләк алган көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Хәбәрнамәгә бүләкнең бәясен раслаучы документлар (касса чегы, товар чегы, бүләк өчен түләү турында башка документ) теркәлә (алар булганда).».

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы** **М.Р. Афанасьева**